**КАРАР**

**14 июль 2023 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты торак пунктында уздырылган «Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Нырты т. п. гражданнар җыенының 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 14 июлендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Нырты т. п. гражданнар җыенының 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 6 абзац 2 пунктта «урам якыртуын тәэмин итү» сүзләрен «су системасын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга»;
- 2 пунктка киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә «Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү)»

«РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 376 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 216 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 216 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты торак пунктында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» Нырты т. п. гражданнар җыенының 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 6 абзац 2 пунктта «урам якыртуын тәэмин итү» сүзләрен «су системасын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга»;

- 2 пунктка киләсе эчтәлеккә яңа абзац өстәргә «Вак таш сатып алу (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү, смета төзү һәм түләү)»

«РИЗА» «КАРШЫ»?»

кабул ителгән дип таныргa.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т. А. Котдусов